МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

27.01.2022 г.Казань № 58

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2021 елның 17 февралендә 8897 номеры белән теркәлде

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2020 елның 3 июлендәге 484 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында социаль хезмәтләр күрсәтү өчен гражданнар чиратын төзү һәм алып бару тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында социаль хезмәтләр күрсәтү өчен гражданнарның чиратын төзү һәм алып бару эшен камилләштерү максатларында боерык бирәм:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының «Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында социаль хезмәтләр күрсәтү өчен гражданнар чиратын төзү һәм алып бару тәртибен раслау турында» 2020 елның 3 июлендәге 484 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының 2021 елның 24 февралендәге 100 номерлы боерыгы керткән үзгәреше белән) белән расланган Татарстан Республикасы социаль хезмәт күрсәтү оешмаларында социаль хезмәтләр күрсәтү өчен гражданнар чиратын төзү һәм алып бару тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.7. Гражданнар социаль хезмәтләр күрсәтү өчен түбәндәге тәртиптә исәпкә куела:

социаль хезмәт күрсәтүнең тиешле рәвешендә социаль хезмәтләр күрсәтү өчен исәптә торган гражданнар исемлегендә стационар (ярымстационар) нигездә социаль хезмәт күрсәтүгә чираттан тыш кабул итүгә хокуклы гражданнар стационар (ярымстационар) нигездә социаль хезмәт күрсәтүгә чираттан тыш кабул итүгә хокуклы булмаган гражданнар алдыннан куела;

стационар (ярымстационар) нигездә социаль хезмәт күрсәтүгә беренче чиратта кабул итүгә хокуклы булган гражданнар социаль хезмәтләр күрсәтү өчен исәптә торган гражданнар исемлегендә социаль хезмәт күрсәтүнең тиешле рәвешендә чираттан тыш кабул итү хокукына ия булган гражданнар артыннан куела;

стационар (ярымстационар) нигездә социаль хезмәт күрсәтүгә кабул иткәндә өстенлеккә ия булган гражданнар социаль хезмәтләр күрсәтүнең тиешле рәвешендә беренче чиратта кабул итүгә хокуклы булган гражданнар артыннан куела;

әлеге пунктның икенче-дүртенче абзацларында күрсәтелгән ташламалы категориягә керми торган гражданнар социаль хезмәтләр күрсәтү өчен, әлеге пунктның алтынчы абзацында каралган очраклардан тыш, стационар (ярымстационар) нигездә социаль хезмәт күрсәтүгә кабул иткәндә өстенлеккә ия булган гражданнар артыннан исәпкә куела.

Гариплеге булган затларны тернәкләндерү үзәгенә, сукыр һәм начар күрә торган затларны социаль тернәкләндерү үзәгенә, мөмкинлекләре чикле булган балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәгенә, халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең комплекслы үзәгендә социаль-тернәкләндерү бүлекчәсенә гариза белән беренче тапкыр мөрәҗәгать иткән, элегрәк әлеге оешмаларда социаль хезмәтләр күрсәтелмәгән, тиешле ташламалы категориягә карый торган гражданнар (алга таба – беренче тапкыр мөрәҗәгать иткән гражданнар) социаль хезмәтләр күрсәтү өчен исемлектә социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар рәвешендә сукырларны һәм начар күрә торган затларны социаль тернәкләндерү үзәгендә, социаль хезмәт күрсәтүнең стационар рәвешендә гариплеге булган затларны тернәкләндерү үзәгендә – социаль хезмәт күрсәтүне сорап яңадан мөрәҗәгать иткән айдан алда килгән ике ел дәвамында социаль хезмәт күрсәтелгән гражданнар алдыннан исәпкә куела һәм социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар рәвешендә гариплеге булган затларны тернәкләндерү үзәгендә, мөмкинлекләре чикләнгән балалар һәм яшүсмерләр өчен тернәкләндерү үзәгендә, социаль хезмәт күрсәтүнең ярымстационар, стационар рәвешләрендә халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең комплекслы үзәгендә социаль-тернәкләндерү бүлекчәсендә ярты ел дәвамында социаль хезмәт күрсәтелгән затлар (яңадан мөрәҗәгать иткән гражданнар) алдыннан әлеге пунктның икенче-дүртенче абзацларында күрсәтелгән һәр ташламалы категория буенча исәпкә куела, ә әлеге пунктның икенче-дүртенче абзацларында күрсәтелгән ташламалы категориягә карамый торган гражданнар, – исемлектә ташламалы категориягә карамагый торган, яңадан мөрәҗәгать иткән гражданнар алдыннан куела.

2.8 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге Тәртипнең 2.3 пунктындагы бишенче абзацында каралган документларны тапшырмау (тулы күләмдә тапшырмау;»;

3.2 пунктта:

беренче абзацта «социаль хезмәт күрсәтүнең хосусый программасы гамәлдә булган» сүзләреннән соң «әлеге Тәртипнең 2.7 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып» сүзләрен өстәргә;

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Социаль хезмәт күрсәтүнең хосусый программасының гамәлдә булу вакыты бетәргә кимендә 15 эш көне алдан оешма гражданнарга (аларның законлы вәкилләренә) гаризада күрсәтелгән ысул белән (язма рәвештә почта адресы буенча, электрон документ формасында, электрон почта адресы, смс-хәбәр), социаль хезмәт күрсәтүнең хосусый программасының гамәлдә булу вакытының бетүе турында хәбәр итә.»;

3.4 пунктта:

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) социаль хезмәт күрсәтүнең хосусый программасының гамәлдә булу вакыты беткән очракта, әмма социаль хезмәт күрсәтүнең хосусый программасының гамәлдә булу вакыты беткән көннән соң килүче 15 эш көненнән дә артмаган чорга;»;

түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«3) гражданинның чираты килеп җиткәч оешмада озата баручы өчен буш урын булмаган очракта, әмма бер айдан да артмаган чорга.»;

4.1 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«гражданинның социаль хезмәт күрсәтүгә кабул итү көнендә (чорында) оешмага килмәве (әлеге Тәртипнең 3.4 пунктында күрсәтелгән очраклардан тыш);»;

3.5 пунктта «3.4 пунктында» сүзләрен «3.4 пунктының икенче, дүртенче абзацларында» сүзләренә алмаштырырга.

Министр Э.Ә. Зарипова